**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№9167**
**14.11.2025**

«Шәҗәрә - нәсел агачы»
шәһәр конкурсын оештыру
һәм үткәрү турында

Башкарма комитетның 2022 елның 19 октябрендәге 5650 номерлы Карары белән расланган 2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәрендә мәдәниятне үстерү муниципаль программасын үтәү йөзеннән, гаилә традицияләрен пропагандалау һәм популярлаштыру, гаиләләрдә буыннар бәйләнешен ныгыту максатларында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның мәдәният идарәсенә «Шәҗәрә - нәсел агачы» шәһәр конкурсын (алга таба – конкурс) оештыруны һәм Яр Чаллы шәһәренең «Эврика» шәһәр мәдәният үзәге» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесендә 2025 елның 8 декабрендә үткәрүне тәэмин итәргә.

2. Расларга:

1) конкурс үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) конкурс оештыру һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә шәһәр конкурсын оештыру һәм үткәрү чыгымнарын финанслауга акча бүлеп бирүне 2025 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Мәдәният» 0801 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 10 000 (ун мең) сум күләмендә тәэмин итәргә, 3 нче кушымтада каралганча.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                    Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 14 ноябрендәге
9167 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Шәҗәрә - нәсел агачы»
шәһәр конкурсын үткәрү турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә «Шәҗәрә - нәсел агачы» шәһәр конкурсының (алга таба - конкурс) максатларын, бурычларын һәм үткәрү тәртибен, эчтәлеген һәм катнашучыларга карата таләпләрне билгели.

2. Конкурсның оештыручылары: Яр Чаллы шәһәренең «Эврика» шәһәр мәдәният үзәге» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесе (алга таба - «Эврика» ШМҮ), Башкарма комитетның мәдәният идарәсе.

2 бүлек. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

3. Конкурс үткәрүнең төп максатлары һәм бурычлары булып тора:

1) буыннар дәвамлылыгын саклау, гаилә һәм гаилә-туганлык бәйләнешләрен ныгыту;

2) үз нәселеңнең, милләтеңнең, туган ягыңның тарихын өйрәнү;

3) Татарстан Республикасы халыкларының милли традицияләрен, гореф-гадәтләрен торгызу;

4) гаилә традицияләрен һәм кыйммәтләрен пропагандалау һәм популярлаштыру;

5) гаилә иҗатын популярлаштыру, үсеп килүче буынга эстетик, әхлакый һәм рухи тәрбия бирүдә аның ролен көчәйтү.

3 бүлек. Конкурс үткәрүнең төп шартлары һәм тәртибе

4. Конкурс 2025 елның 8 декабрендә В. Гостев урамы, 29 йорт адресы буенча үтәчәк. Конкурс үткәрү тәртибе, сроклары, үткәрү шартлары турында мәгълүматны «Эврика» ШМҮ рәсми сайтыннан http://evrika-chelny.ru/, https://vk.com/club102744487 һәм 36-65-26 телефон номеры буенча алып була.

5. Конкурста катнашу бушлай.

6. Конкурста нинди милләттән һәм диндә булуына карамастан, гаилә-туганлык төркеменең берничә буын катнашучыларын берләштергән гаилә коллективлары (гаилә-туганлык төркемнәре) яшь буенча чикләүләрсез катнаша.

7. Конкурста катнашу өчен заявка бирүчеләргә түбәндәгеләрне эшләргә кирәк:

1) катнашу өчен анкета-заявканы әлеге нигезләмәнең беренче кушымтасындагы форма буенча тутырырга һәм 2025 елның 30 ноябренә кадәр evrika.konkurs@mail.ru электрон почтасына җибәрергә;

2) гаилә-туганлык төркеменең конкурста катнашырга планлаштырган һәр әгъзасына әлеге нигезләмәнең 2 нче кушымтасындагы форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык тутырырга һәм evrika.konkurs@mail.ru электрон почтасына җибәрергә;

3) альбом, стенд, панно, баннер-коллаж рәвешендә ясалган, шәҗәрәнең текст рәвешендәге нигезләмәсен үз эченә алган гаилә-туганлык төркеменең шәҗәрә агачын (шәҗәрә) бирергә.

Текстка таләпләр: А4 форматы, Times New Roman шрифты, шрифт зурлыгы - 14, гаилә династияләре тасвирламасы булу.

8. Конкурсны әзерләү һәм үткәрү өчен составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә.

Оештыру комитеты тәэмин итә:

1) конкурс үткәрүне;

2) жюри карарын беркетмә белән рәсмиләштерүне;

3) конкурсны әзерләү һәм үткәрү буенча эшләрне координацияләүне гамәлгә ашыруны;

4) оештыру мәсьәләләрен хәл итүне;

5) жюри составын формалаштыруны.

9. Жюри йомгак ясау өчен җавап бирә һәм конкурсның төрле номинацияләрендә җиңүчеләрне билгели.

## 4 бүлек. Конкурс этаплары

10. Конкурс ике этапта үткәрелә:

1) «Безнең династия» - гаилә командасының визит карточкасы:

- концерт номеры (бию, җыр, театральләштерелгән куелыш, гаиләнең милли костюмы презентациясе);

- һөнәри династия, аның җәмгыять һәм гаилә тормышындагы роле тасвирламасы

(регламент - ун минутан артмасын);

2) «Минем шәҗәрәм» - катнашучылар гаиләнең шәҗәрәсе турында тикшеренү эшен – бер гаилә үрнәгендә нәсел агачын һәм гаиләнең бер әгъзасы турында хикәя (эссе) тәкъдим итәләр. Тикшерелә торган буыннар биштән ким булмаска тиеш (регламент - биш минуттан артмасын).

## 5 бүлек. Конкурс җиңүчеләрен билгеләү шартлары һәм тәртибе.

11. Жюри катнашучыларның чыгышларын, биремнәрне үтәү нәтиҗәләрен һәм конкурсның башка төр сынауларын 10 баллы система буенча тикшерә һәм бәяли. Жюри эшенең нәтиҗәсе булып тутырылган һәм имзаланган, баллар куелган индивидуаль эксперт битләре тора. Конкурсны үткәрү нәтиҗәләре беркетмә белән рәсмиләштерелә. Конкурс нәтиҗәләре беркетмәгә кул куйганнан соң, өч эш көненнән дә соңга калмыйча, «Эврика» ШМУ» рәсми сайтында: https://vk.com/club102744487 бастырылачак. Һәр катнашучының йомгаклау бәясе алынган балларның уртача арифметик бәясеннән, бәя критерийлары нигезендә төзелә.

12. Конкурс эшләрен бәяләү критерияләре:

1) «Безнең династия»:

- номерны оригиналь башкару, гаилә коллективының барлык әгъзаларының да катнашуы, музыка коралларын куллану, артистлык осталыгы;

- гаилә кыйммәтләрен пропагандалау дәрәҗәсе, традицион гаилә кыйммәтләренә бирелгәнлек, үз фамилиясенең килеп чыгышы турында белешмәләрнең нигезлелеге һәм дөреслеге; төбәк һәм ил тарихында һәм тормышында нәсел вәкилләре роле турындагы белемнәрнең тирәнлеге, вакытны чикләү регламентын үтәү;

2) «Минем шәҗәрәм» - тикшеренү эшенең эчтәлеге (тикшеренүнең тирәнлеге һәм төгәллеге, төрле чыганаклардан файдалану), шәҗәрә агачының ясалышы (күрсәтмәлелек, тулылык, стандартларга туры килү), эссе/хикәянең сыйфаты (образны ачу, әдәби өлеш,

эмоциональ тирәнлек, шәҗәрә агачы белән бәйләнеш), үз гаиләсенең килеп чыгышы һәм милли тамырлары турындагы белемнәрнең тирәнлеге, шулай ук мәгълүмат бирүнең оригинальлеге, иҗади якын килү исәпкә алына, вакытны чикләү регламентын үтәү.

## 6 бүлек. Конкурс җиңүчеләрен бүләкләү

13. Конкурс җиңүчеләре I, II һәм III дәрәҗә дипломнар белән бүләкләнә. Калган катнашучылар конкурста катнашучы дипломнары ала.

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе
урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе
башлыгы вазыйфаларын башкаручы Г.А. Шәфыйкова

«Шәҗәрә - нәсел агачы»
шәһәр конкурсын үткәрү
турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

«Шәҗәрә - нәсел агачы»
шәһәр конкурсында катнашуга заявка

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Катнашучының Ф.И.А.и., туган көне | |
| 2. | Яшен һәм катнашучыга карата туганлык мөнәсәбәтен күрсәтеп, гаиләдән катнашучыларның (булса) Ф.И.А.и. | |
| 3. | Гаилә турында кыскача мәгълүмат | |
| 4. | Элемтә өчен мәгълүмат (телефон, e-mail) | |
| 5. | Тәкъдим ителгән эшнең номинациясе | |

_______________ Дата, имза

«Шәҗәрә - нәсел агачы»
шәһәр конкурсын үткәрү
турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

Мин_________________________________________________________________________,
_
теркәлү адресым:_______________________________________________,
шәхесне таныклаучы документ:_______________________________________________
(күрсәтелгән документны бирү датасы һәм аны биргән орган турында мәгълүматлар), Россия Федерациясенең «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә «Шәҗәрә - нәсел агачы» («Моя родословная») конкурсын оештыручыларга, конкурс нигезләмәсе белән билгеләнгән таләпләргә туры килүне тикшерү максатында, аларны эшкәртү күрсәтелгән мәгълүматларның конфиденциальлеген саклау турында бурычларны үз өстенә алган вәкаләтле затлар тарафыннан гамәлгә ашырылу шарты белән, минем шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә ризалыгымны раслыйм. Минем шәхси мәгълүматларымны башка затларга тапшыру яки аларны башкача ачып салу минем язма ризалыгым белән генә гамәлгә ашырылырга мөмкин. Мин тиешле язма документ төзү юлы белән ризалыгымны кире алу хокукын үземдә калдырам, әлеге документ конкурсны оештыручылар адресына минем тарафтан почта буенча белдерү белән заказлы хат итеп җибәрелергә яисә конкурсның вәкаләтле вәкиленә расписка белән шәхсән тапшырылырга мөмкин.

Әлеге ризалыкны бирдем: «___» _____________ 2025 ел.

Имза: _______________/__________/